ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 август 2019 ел № 4266

Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3843 нче карары белән расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентка үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 апрелендәге 50-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3843 нче карары белән расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 11, 12 пунктчалар белән тулыландырырга:

«11) үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда дәүләт сере булып саклана торган мәгълүматларны һәм федераль законнарда каралган очраклардан кала, федераль законнар нигезендә алу чикләнгән башка мәгълүматны алганда, аларны ачып салмаска;

12) күрсәтмәне үтәмәүче затка карата Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылык чаралары кулланырга.»;

2) 35 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«35. Планнан тыш тикшерү үткәрүне башлау өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) сатып алуда катнашучының заказчы, вәкаләтле орган, вәкаләтле учреждение, махсуслаштырылган оешма, электрон мәйданчык операторы,

махсуслаштырылган электрон мәйданчык операторы яки сатып алуларны гамәлгә ашыра торган комиссияләр, аларның әгъзалары, контракт хезмәтенең вазыйфаи затлары, контракт идарәчесенең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять ителгән мөрәҗәгать алу. Мондый шикаятьне карап тикшерү 44-ФЗ санлы Законның 6 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла, 44-ФЗ санлы Законның 99 маддәсенең 15.1 бүлегендә каралган эш итүләргә (эш итмәүләргә) шикаять итү очрагыннан кала. Планнан тыш тикшерү сатып алуда катнашучының шикаяте нигезендә үткәрелгән очракта, әлеге тикшерүне үткәрү һәм мондый шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бердәм карар кабул ителә;

2) Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы башка норматив хокукый актлар бозылу хакында мәгълүмат алу, шул исәптән:

- физик затның, юридик затның яисә җәмәгать берләшмәсенең җәмәгать контролен гамәлгә ашыра торган яки юридик затлар берләшмәләренең Россия Федерациясе законнарын бозу һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы башка норматив хокукый актлар бозылу билгеләре булу хакында күрсәтелгән гаризалары һәм хәбәрләре;

- контрольлек итүче орган тарафыннан сатып алулар өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы башка норматив хокукый актлар бозылу ачыклану;

- массакүләм мәгълүмат чараларының Россия Федерациясе законнарын бозу һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы башка норматив хокукый актлар бозылу билгеләре булу хакында күрсәтелгән хәбәре;

3) 44-ФЗ санлы Законның 99 маддәсендәге 22 бүле 2 пункты нигезендә үтәү өчен бирелгән элекке срокның чыгуы.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны, шулай ук аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин